# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## «Утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны сатып алу, саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

1 статья. «Утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны сатып алу, саклау һәм куллану кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны конфискацияләп яисә аннан башка гына, хезмәт өчен түләүнең уннан бер минималь күләменнән алып өчтән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменнән алып икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

2. 2 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең уннан бер минималь күләменнән алып икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменнән алып бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

3. 3 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын һәм сиптергеч баллоннарны конфискацияләп яисә аннан башка гына, хезмәт өчен түләүнең

уннан бер минималь күләменнән алып икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«утлы, газлы коралны, сугыш кирәк-яракларын, сиптергеч баллоннарны конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменнән алып бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

4. 4 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең уннан бер минималь күләменнән алып өчтән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

5. 5 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«утлы, газлы коралны һәм сугыш кирәк-яракларын конфискацияләп яисә аннан башка гына, хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменнән алып икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

6. 7 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«утлы, газлы коралны һәм сугыш кирәк-яракларын тартып алып, аларның хакын иясенә кире кайтарып, хезмәт өчен түләүнең уннан бер минималь күләменнән алып өчтән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

7. 8 статьяда «суд» сүзен «административ комиссия» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 20 декабре
№ 544